**Татарстан Республикасы**
**Арча муниципаль районының**
**Арча шәһәр муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәр**
**башкарма комитеты**
**422000, Арча ш., Совет мәйданы, 27**
**тел. 3-15-25, 3-12-35**

**Муниципальное образование**
**город Арск**
**Арского муниципального района**
**Республики Татарстан**
**исполнительный комитет**
**города Арск**
**422000, г. Арск, площадь Советская , 27**
**тел. 3-15-25, 3-12-35**

**КАРАР**

**«_17_ »___ноябрь___ 2016** **№ __160__**

**Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү, күрсәтелгән актларны карап тоту һәм аларның үтәлешен тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә таләпләрне раслау хакында**

"Дәүләт һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турында" Федераль законның 19 статьясындагы 4 өлешенең 1 пункты, «сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру, күрсәтелгән актларны карап тоту һәм аларның үтәлешен тәэмин итү турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итүнең гомуми таләпләрен раслау хакында" 18.05.2015 ел, № 476 Россия Федерациясе Хөкүмәте Карары нигезендә, Арча шәһәре башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү, күрсәтелгән актларны карап тоту һәм аларның үтәлешен тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә кушып бирелә торган таләпләрне расларга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru.

3. Карар бастырылган көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча шәһәре башкарма комитеты җитәкчесенең торак-коммуналь һәм җир мәсьәләләре буенча урынбасары К. В. Гомәровка йөкләргә.

Арча шәһәре башкарма
комитеты җитәкчесе Р. Ф. Касыймов

Кушымта

**Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү, күрсәтелгән актларны карап тоту һәм аларның үтәлешен тәэмин итү өчен сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итү тәртибенә таләпләр**

1. Әлеге документ Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының түбәндәге хокукый актларын эшләү һәм кабул итү, карап тоту, үтәүне тәэмин итү тәртибенә таләпләрне билгели, раслый:

җирле үзидарә органнары функцияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнарны билгеләү кагыйдәләре (алга таба-норматив чыгымнар);

муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен сатып алына торган товарларның, эшләрнең, хезмәтләрнең аерым төрләренә (шул исәптән товарларның, эшләрнең, хезмәтләрнең чик бәяләренә) таләпләрне билгеләү кагыйдәләре;

норматив чыгымнар;

товарларның, эшләрнең, хезмәтләрнең аерым төрләренә (шул исәптән товарларның, эшләрнең, хезмәтләрнең чик бәяләренә) таләпләр.

2. Әлеге документның 1 пунктында күрсәтелгән хокукый актлар Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты тарафыннан карарлар проектлары рәвешендә эшләнә.

3.Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының " Арча шәһәре» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты (Алга таба-Башкарма комитет) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирле бюджет акчаларын баш бүлүче булып тора һәм товарлар, эшләр, хезмәтләр күрсәтү бәяләре, саны һәм (яисә) нормативлары нормативларын расларга хокуклы.

4. Әлеге документның 1 пунктында күрсәтелгән хокукый актлар проектларына җәмәгать контроле максатларында, Сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру, күрсәтелгән актларны карап тоту һәм аларның үтәлешен тәэмин итү турында Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 18 маендагы Карары белән расланган хокукый актларны эшләү һәм кабул итү тәртибенә гомуми таләпләрнең 6 пункты нигезендә фикер алышу уздыру өчен; "Сатып алулар өлкәсендә нормалаштыру, күрсәтелгән актларны карап тоту һәм аларны үтәүне тәэмин итү турында хокукый актлар эшләү һәм кабул итүнең гомуми таләпләрен раслау турында" 476 номерлы (алга таба - гомуми таләпләр, җәмәгать контроле максатларында фикер алышу), Башкарма комитет әлеге хокукый актларның проектларын сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында билгеләнгән тәртиптә урнаштыра.

5. Фикер алышу срогы җәмәгать контроле максатларында әлеге документның 1 пунктында күрсәтелгән хокукый актлар проектларын сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында урнаштырганнан соң 8 календарь көне билгеләнә.

6. Башкарма комитет, гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында Россия Федерациясе законнары нигезендә, әлеге документның 5 пункты нигезләмәләрен исәпкә алып, күрсәтелгән органнар тарафыннан билгеләнгән срокта электрон яисә язма рәвештә кергән иҗтимагый берләшмәләрнең, юридик һәм физик затларның тәкъдимнәрен карый.

7. Башкарма комитет җәмәгать берләшмәләре, юридик һәм физик затлар тәкъдимнәрен караганнан соң 2 эш көне эчендә әлеге тәкъдимнәрне һәм җавапларны билгеләнгән тәртиптә сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында урнаштыра.

8. Фикер алышу нәтиҗәләре буенча, җәмәгать контроле максатларында, Башкарма комитет, кирәк булганда, әлеге документның 1 пунктында күрсәтелгән хокукый актлар проектларына иҗтимагый берләшмәләр, юридик һәм физик затлар тәкъдимнәрен исәпкә алып үзгәрешләр кертү турында һәм Башкарма комитет каршындагы Иҗтимагый совет утырышларында күрсәтелгән хокукый актлар проектларын карау турында гомуми таләпләрнең 3 пункты (алга таба - Иҗтимагый совет) нигезендә карарлар кабул итә.

9. Иҗтимагый совет составына җирле бюджетлар һәм иҗтимагый оешмалар акчаларын баш бүлүчеләр вәкилләре керә.

10. Әлеге документның 1 пунктында күрсәтелгән хокукый актлар проектларын карау нәтиҗәләре буенча Иҗтимагый совет түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) хокукый акт проектын эшләп бетерү кирәклеге турында;

б) хокукый актны кабул итү мөмкинлеге турында.

11. Иҗтимагый совет тарафыннан кабул ителгән карар, тиешле карар кабул ителгәннән соң 3 эш көненнән дә соңга калмыйча, Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән тәртиптә сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында урнаштырыла торган барлык әгъзалар тарафыннан имзалана торган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

12. Сатып алу объектын һәм (яисә) объектларын нигезләгәндә әлеге документның 1 пунктындагы өченче абзацында күрсәтелгән хокукый актларга кертелгән үзгәрешләр, субъектлар тарафыннан Башкарма комитет билгеләгән тәртиптә бюджет ассигнованиеләрен бүлүне Бюджет планлаштыруы тапшырганчы исәпкә алына.

13. Әлеге документның 1 пунктындагы өченче һәм дүртенче абзацларында каралган хокукый актлар Башкарма комитет тарафыннан елга кимендә бер тапкыр карала.

14. Әлеге документның 10 пунктындагы "а" пунктчасында күрсәтелгән карар кабул ителгән очракта, Башкарма комитет әлеге документның 1 пунктындагы өченче абзацында

һәм дүртенче абзацында күрсәтелгән хокукый актларны Җәмәгать советы кабул иткән карарлар нигезендә эшләп бетергәннән соң раслый.

15. Арча муниципаль районы Башкарма комитетының икътисад һәм финанс бүлеге әлеге документның 1 пунктындагы өченче һәм дүртенче абзацында күрсәтелгән хокукый актларны кабул иткән көннән 7 эш көне эчендә әлеге хокукый актларны билгеләнгән тәртиптә сатып алулар өлкәсендә бердәм мәгълүмат системасында урнаштыра.

16. Әлеге документның 1 пунктындагы өченче һәм дүртенче абзацында күрсәтелгән хокукый актларга үзгәрешләр кертү аларны кабул итү өчен билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

17. Муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен сатып алына торган товарларның, эшләрнең, хезмәтләрнең аерым төрләренә (шул исәптән товарларның, эшләрнең, хезмәтләрнең чик бәяләренә) таләпләрне билгеләү кагыйдәләрен раслаучы Башкарма комитет карары:

а) Башкарма комитет раслаган Товарларның аерым төрләре исемлегенә кертелгән товарларның, эшләрнең, хезмәтләрнең (шул исәптән товарларның, эшләрнең, хезмәтләрнең иң чик бәяләренең) характеристикаларының (үзлекләренең) әһәмиятен билгеләү тәртибе;

б) Башкарма комитет, казна учреждениеләре һәм бюджет учреждениеләре сатып ала торган товарларның, эшләрнең, хезмәтләрнең аерым төрләрен (шул исәптән товарларның, эшләрнең, хезмәтләрнең иң чик бәяләрен) сайлап алу тәртибе (алга таба - ведомство Исемлеге);

в) ведомство Исемлеге формасы.

18. Норматив чыгымнарны билгеләү кагыйдәләрен раслаучы Башкарма комитет карары ачыкларга тиеш:

а) норматив чыгымнарны исәпләү тәртибе, шул исәптән исәпләү формулалары;

б) Башкарма комитетның исәп-хисап тәртибе башкарма комитет тарафыннан билгеләнмәгән норматив чыгымнарны исәпләү тәртибен билгеләү бурычы;

в) Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнары тарафыннан товарлар, эшләр, хезмәтләр, шул исәптән хезмәткәрләр вазыйфалары һәм (яисә) категорияләре буенча төркемләнгән хезмәткәрләр саны һәм (яисә) бәяләре нормативларын билгеләү турында таләп.

19. Башкарма комитет үзе сатып ала торган товарларның, эшләрнең, хезмәтләрнең аерым төрләренә һәм ведомство карамагындагы казна учреждениеләренә һәм бюджет учреждениеләренә карата таләпләрне раслаучы хокукый актларда түбәндәге белешмәләр булырга тиеш:

а) товарларның, эшләрнең, хезмәт күрсәтүләрнең аерым төрләренә (шул исәптән товарларның, эшләрнең, хезмәтләрнең чик бәяләренә) карата таләпләр билгеләнә торган заказчы (заказчы бүлекчәләре)исемнәре;

б) характеристикаларын (үзлекләрен) һәм аларның әһәмиятен күрсәтеп, товарларның, эшләрнең, хезмәтләрнең аерым төрләре исемлеге.

20. Башкарма комитет һәр хезмәткәр өчен билгеләнгән индивидуаль һәм (яки) коллектив, берничә хезмәткәр өчен билгеләнгән, күрсәтелгән органнарның структур бүлекчәләре буенча товарлар, эшләр, хезмәтләр саны һәм (яки) бәясе нормативларын эшләп чыгара һәм раслый.

21. Башкарма комитетның норматив чыгымнарны раслаучы хокукый актларын билгеләргә кирәк:

а) норматив чыгымнарны билгеләү кагыйдәләре белән исәпләү тәртибе билгеләнмәгән норматив чыгымнарны исәпләү тәртибе;

б) товарлар, эшләр, хезмәтләр, шул исәптән хезмәткәрләр вазыйфалары һәм (яки) хезмәткәрләр категорияләре буенча төркемләнгән товарлар саны һәм (яки) бәясе нормативлары.

22. Әлеге документның 1 пунктындагы өченче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән хокукый актлар бер яки берничә заказчы сатып ала торган товарларның, эшләрнең, хезмәтләрнең аерым төрләренә таләпләрне һәм (яки) Арча муниципаль районы башкарма комитеты функцияләрен тәэмин итүгә норматив чыгымнарны билгели ала.

23. Товарларның аерым төрләренә, эшләренә, хезмәтләренә карата таләпләр һәм норматив чыгымнар объектны һәм (яки) тиешле заказчы сатып алу объектларын нигезләү өчен кулланыла.